Гимназиябездә Тукай көннәре.

Без ел ел саен, җир өсте яшеллеккә күмелеп, агачларда хуш исле бөреләр уянган чакта, бөек шагыйребез Г.Тукайның туган көнен билгеләп үтәбез.



Быел ул аеруча истәлекле, чөнки әдибебезнең 125 еллык юбилее.

Г.Тукайга багышланган айлык шигырь укучылар бәйгесе белән башланып китте.Мәктәпкүләм ярышта татар төркемнәре арасында Гайсина Аделина(4а), Сабитова Зилә (6а), Галиева Әдилә(7а),рус төркемнәре арасында Степаненко Александра(6в) җиңүче дип табылдылар. Гимназиябезнең 7а сыйныф укучысы Галиева Ә., СтепаненкоА. шәһәркүләм нәфис сүз бәйгесендә җиңү яулап I, II нче дәрәҗә дипломга лаек булдылар.

Бәйрәм рухын дәвам итеп, һәр сыйныф укучылары белән Г.Тукайның тормышы һәм иҗатына багышланган дәресләр үткәрелде. Балалар Тукай иҗаты буенча үткәрелгән рәсем конкурсында да актив катнаштылар.

Олуг шагыйребезнең туган көнендә татар төркемендә укучы 1-4 сыйныф укучылары белән “Тукай безнең күңелләрдә” дигән бик матур әдәби-музыкаль чара үткәрелде.Укытучылары Галиева Г.И. җитәкчелегендә алар Г.Тукайның шигырьләрен сөйләделәр, экиятләрен сәхнәләштереп күрсәттеләр. Шагыйрь сүзләренә язылган җырларны бик оста башкардылар. Бәйрәмдә катнашучылар зур канәгатьләнү һәм горурлык хисләре кичерделәр.

Укучыларда халкыбызның гасырлар буе яшәп килгән гореф-гадәтләрен, әхлак кагыйдәләрен, йолаларын,милли бәйрәмнәрен ихтирам итәргә өйрәтәбез.Ел саен бу бәйрәмнәр гимназиябездә этаплап үткәрелә.Мәсәлән: 2нче сыйныфта”Без Тукай оныклары”,3 нче сыйныфта”Нәүрүз”бәйрәме,
4 нче сыйныфта”Сөмбелә”, 5 нче сыйныфта”Сабантуй” була.Бу бәйрәмнәр гимназиябез тормышында әһәмиятле урынны алып торалар.




